СОВЕТ
СРЕДНЕАТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная , д. 2а, д.Нижние Аты,
Арский муниципальный район, 422016

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА АТЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урамы, 2 йорт, Түбән Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422016

**Тел. (84366)507-35, факс (84366)507-35. E-mail: Sat .Ars@tatar.ru**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге башлыгы карары**

**22 март 2024 ел** **№ 3**

**"Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлегенең Кылачы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" 2023 елның 16 ноябрендәге 2 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлегенең Кылачы авылында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Урта Аты авыл җирлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1.Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге Кылачы авылында , Аяк киеме урамы, 17 йорт адресы буенча гражданнарның үзарасалым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2024 елның 5 апреленә 10 сәгать 00 минутта халык җыенын билгеләргә.

2.«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлегенең Кылачы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 16 ноябрендәге 2 нче номерлы карарында гражданнар җыены соравын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге Кылачы авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 500 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш, 250 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (алар белән бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын,

балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту; (вак таш сатып алу)

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»»

3.«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлегенең Кылачы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 16 ноябрендәге 2 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Кылачы авылы, Аяк киеме урамы, 17 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http:pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Урта Аты авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Батталова

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН * АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН * МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «СРЕДНЕАТЫНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» * ГЛАВА СРЕДНЕАТЫНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1609002912